ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25.05.2022 г. Заинск № 255

**«Торак урыны гомуми мәйданының бер квадрат метрына уртача базар бәясен раслау турында»**

Россия Федерациясе Торак кодексы, «2022 елның I яртысына Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урыны гомуми мәйданының бер квадрат метрына уртача базар бәясе нормативы һәм 2022 елның I кварталына Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урыны гомуми мәйданының бер квадрат метрына уртача базар бәясе күрсәткечләре турында» 2021 елның 17 декабрендәге № 955/пр номерлы Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак - коммуналь хуҗалык министрлыгы боерыгы нигезендә, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Федераль бюджет акчалары исәбеннән торак урыннары сатып алуга (төзүгә) социаль түләүләр бирелә торган барлык категория гражданнар өчен, шул исәптән «Яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» программасында катнашу өчен, социаль түләүләр күләмен исәпләү өчен 2022 елның беренче яртысына Зәй муниципаль районы буенча гомуми торак мәйданының бер квадрат метрына уртача базар бәясен (сумнарда) 69261 (алтмыш тугыз мең ике йөз алтмыш бер) сум күләмендә расларга.
2. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны Зәй муниципаль районының http://zainsk.tatarstan.ru рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында урнаштырырга.
3. Карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **Э.Э.Галеев**

С.А.Филюшина
Юрист